


19 июльдә Белгород шәһәрендә VIII Россия укучыларынын Жәйге Спартакиада кысаларында авыр атлетика буенча ярышлар vтте. Анда 2000 -2001 елда туганнар кочләрен сынады.
Ярышларда 42 регионнан 195 яшь спортсмен катнашты. Алтмыш ике килограмм авырлыктагылар арасында Рузаевка шәһәренен икенче номерлы мәктәбендә укучы штангист Дамир Морозкин ярышты. Анын тренеры -Абдулла Сафиулла улы Толстяков. Ул - атаклы авыратлет, кvп тапкыр Мордовия чемпионы, СССР спорт мастеры. Балаларны «Локомотив» спортзалында бушлай, жәмәгатьчелек нигезендә ойрәтә. Тренеры Абдулла Сафиулла улы Толстяков белән штангист Дамир Морозкиннын бу ярышка куйган бурычлары – мастер нормасын vтәv. Монын очен ике тор нәтижәсендә 230 килограмм жыю кирәк иде. Әлеге ярышта унышлары коткәннән артты. Кинәт кvтәрvдә 102,5 килограмм -  бу Дамирнын шәхси рекорды иде. Бу юлы Дамирнын жинvе бик унышлы булды. Ярышта штанганы беренче тапкыр кvтәргәндә – 126, ә икенче тапкыр - 115 килограмм булды, шуна оченче тапкыр кvтәрvдән баш тартты. Шул рәвешле әйтеп киткән ярышта лаеклы икенче урын яулады ул, беренчелекне ярты яшькә олы булган халыкара класслы Россиянен спорт мастеры алды. Шулай итеп, Дамир Морозкин Рузаевка авыратлетлар арасында штанга кvтәрv буенча беренче Россия мастеры исемен яулады. Ана әле уналты яшь тә тулмаган. Дамир - тренерынын икенче Россия спорт мастеры, беренчесе - Алексей Киселев.
Алда Дамир Морозкинны тагы да югары унышлары котә.

**Н.Хәлил**